МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.06.2024 Казан ш. № 11-50

"Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе турында" Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.05.2016 елның 11-60 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

“Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында” Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге 821 нче номерлы Указына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, б о е р ы к б и р ә м:

“Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе турында" Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.05.2016 елның 11-60 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 21.03.2018 ел, № 11-35, 07.04.2023 ел, № 11-28, 28.08.2023 № 11-92 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәдә:

1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре, Министрлык) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы

Федераль закон белән билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки аны җайга салу турындагы таләпләрне, һәм коррупциягә каршы көрәшү максатында башка федераль законнар белән чикләүләрне һәм тыюларны (алга таба-хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр) үтәүне тәэмин итүдә;»;

3.1 пунктына  түбәндәге эчтәлектәге "е" пунктчасын өстәргә:

“е) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә караа таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә комачаулаучы аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итәргә.»;

3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр Министрлыкның коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы хезмәткәре тарафыннан карала.»;

3.4.2 пунктында “3.1 пунктының "д" пунктчасында   дигән сүзләрне 3.1 пунктының "д «һәм “е” пунктчаларында" дигән сүзләргә алыштырырга;

3.4.3 пунктында:

в подпункте «а» пунктчасында  3.1 пунктның «д» пунктчасы» дигән сүзләрне 3.1 пунктның "д» һәм “е” пунктчаларында”  дигән сүзләргә алыштырырга;

«в» пунктчаны  түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"в) «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “д” һәм “е” пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне башлангыч рәвештә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле йомгак, шулай ук әлеге Нигезләмәнең яки башка карарның 3.13, 3.15.1, 3.18, 3.18.1 пунктларына ярашлы рәвештә карарларның берсен яки башка карар кабул итү өчен рекомендацияләр.»;

3.7 пунктны   түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (планда каралган) утырышында карала.»;

3.8 пунктта 3.1 пунктның «б» пунктчасы нигезендә” дигән сүзләрне “3.1 пунктның «б” һәм “е” пунктчалары нигезендә” дигән сүзләргә алыштырырга;

3.8.1 пунктның "а" пунктчасында “3.1 пунктның “б” пунктчасы нигезендә” дигән сүзләрне “3.1 пунктның «б” һәм “е” пунктчалары нигезендә” дигән сүзләргә алыштырырга;

Түбәндәге эчтәлектәге 3.18.1 пунктын өстәргә:

«3.18.1. Комиссия”, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "е" пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча

түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе белән аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин булмавының бер-берсенә бәйле рәвештә барлыкка килүен тану турында;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе белән аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин булмавының бер-берсенә бәйле булмавын тану турында.»;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Комиссия, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 3.11 - 3.15.1, 3.17 - 3.18.1 пунктларында күздә тотылганнан үзгә карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм сәбәпләре комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.»;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм әлеге боерык белән расланган мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе составында:

комиссия составыннан Никонов Руслан Викторовичны чыгарырга;

комиссия составына Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе оештыру бүлеге баш киңәшчесе Корнилов Юрий Владимировичны кертергә.

Министр вазыйфаларын башкаручы М.Д. Фәйзрахманов